Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Полянка авыл җирлеге
Советы

КАРАР

№ 66-1 «05» декабрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Советының «җир салымы турында»2023 елның 23 октябрендәге 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм РФ Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.«Җир салымы турында» 2023 елның 23 октябрендәге 63 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 1 пунктчасының өченче абзацында «һәм объектлары» сүзләрен «һәм (яисә) объектлары» сүзләренә алмаштырырга, «объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлеш» сүзләрен «күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлеше» сүзләренә алмаштырырга, «һәм объектларга» сүзләрен «һәм (яисә) объектларга» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Полянка авылы, Балымер авылы һәм Танкеевка авыл торак пунктларында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының интернет://spasskiy.tatarstan.ru/ челтәрендәге рәсми сайтында һәм https://pravo.tatarstan.ru/ рәсми хокукый мәгълүмат сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Полянка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Царев

СОВЕТ ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПОЛЯНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА